**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8871**
**22.09.2023**

Яр Чаллы шәһәре халкына
үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль
автоматлаштырылган системасы турында
нигезләмәне раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 26 июлендәге 655 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы турында нигезләмәне расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 22 сентябрендәге
8871 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең
муниципаль автоматлаштырылган системасы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәре халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасының (алга таба – ҮХИМАС) билгеләнешен, бурычларын һәм аңа карата таләпләрне, аны куллану һәм даими әзерлек хәлендә тоту тәртибен билгели.

2. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 1 мартындагы 10-ТРЗ номерлы номерлы законы һәм гражданнар оборонасы һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнгән.

3. Әлеге нигезләмәдә файдаланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр Татарстан Республикасының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Законы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы һәм Россия Федерациясе цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Халыкка хәбәр итү системалары турында нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 578/365 номерлы приказы (алга таба - 578/365 номерлы приказ) һәм гражданнар оборонасы һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

4. 578/365 номерлы приказда язылган таләпләр нигезендә, ҮХИМАС ул мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналларын халыкка, идарә органнарына һәм гражданнар оборонасы һәм Яр Чаллы шәһәренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының шәһәр звеносына (алга таба - ГТХТС шәһәр звеносы) җиткерүне тәэмин итә торган көчләрнең, элемтә һәм хәбәр итү чараларының, тапшыру челтәрләренең, гомуми файдаланудагы элемтә челтәре каналларының оештыру-техник берләшмәсеннән гыйбарәт.

5. ҮХИМАС Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү дәүләт системасының состав өлеше булып торучы һәм халыкка, идарә органнарына һәм гражданнар оборонасы көчләренә һәм ГТХТСка хәбәр итү сигналларын һәм яки ашыгыч мәгълүмат җиткерүне тәэмин итүче Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы белән идарә итү системасына тоташтырыла һәм махсус программа-техник хәбәр итү чараларыннан халыкка ашыгыч хәбәр итү комплекслы системасы (алга таба-ХАХИКС) чараларыннан, кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка мәгълүмат бирү һәм хәбәр итү гомумроссия комплекслы системасы чараларыннан, хәрәкәтле объектларда кычкырып сөйли торган чаралардан, мобиль һәм күтәреп йөртелә торган хәбәр итү чараларыннан, шулай ук аның эшләвен тәэмин итә торган каналлардан, Россия Федерациясе бердәм электр элемтәсе челтәренең элемтә линияләреннән һәм

мәгълүматлар тапшыру челтәрләреннән тора торган үзара бәйләнештәге элементлар комбинациясеннән тора.

6. Хәбәр итү сигналы идарә органнары һәм гражданнар оборонасы көчләре, ГТХТС шәһәр звеносы тарафыннан гражданнар оборонасы һәм халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар үткәрү, шулай ук халык тарафыннан саклану чараларын һәм ысулларын куллану өчен команда булып тора. Факттагы һәм прогнозлана торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар, гражданнарның тормышына яки сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, авырулар, шулай ук үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм саклану ысуллары турында ашыгыч мәгълүмат кичекмәстән халыкка хәбәр итү муниципаль системасы аша тапшырыла.

7. Муниципаль хәбәр итү системасының гамәлдә булган зона чикләре булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ чикләре тора. ХАХИКСның гамәлдә булу (эшләү) зона чикләре булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган халыкка ашыгыч хәбәр итү зоналары чикләре тора.

8. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту гражданнар оборонасын әзерләү һәм алып бару, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар комплексының состав өлеше булып тора.

## 2 бүлек. Халыкка хәбәр итү муниципаль системасының билгеләнеше һәм төп бурычлары

9. Муниципаль хәбәр итү системасының төп бурычы булып хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны түбәндәгеләргә җиткерү тора:

1) гражданнар оборонасы һәм ГТХТС звеносының җитәкче составына;

2) Яр Чаллы шәһәренең гражданнар оборонасы көчләренә һәм ГТХТС звеносы көчләренә;

3) Яр Чаллы шәһәренең бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә (алга таба – шәһәр БДДХ) һәм социаль әһәмиятле объектларның дежур хезмәтләренә (җитәкчеләренә);

4) Яр Чаллы шәһәре территориясендә булган кешеләргә.

10. ХАХИКСның төп бурычы булып хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны халыкка ашыгыч хәбәр итү зоналарында булган кешеләргә, шулай ук ГТХТСның тиешле дәрәҗәдәге көндәлек идарә органнарына җиткерүне тәэмин итү тора.

## 3 бүлек. Халыкка хәбәр итү муниципаль системасын куллану тәртибе

11. Халыкка хәбәр итү системаларын билгеләнеше буенча куллану әлеге Нигезләмәгә, гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планнарына һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча эш планнарына нигезләнеп планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла.

12. ГТХТС шәһәр звеносы белән көндәлек идарә итү органнарының дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре, Гражданнар оборонасы белән идарә итү һәм ГТХТС системасында хәбәр итү сигналларын һәм (яки) ашыгыч мәгълүмат алганнан соң, аны алганны раслыйлар һәм кичектергесез Башкарма комитет Җитәкчесенә, шулай ук идарә органнарына һәм тиешле дәрәҗәдәге гражданнар оборонасы һәм ГТХТС көчләренә җиткерәләр.

13. Халыкка хәбәр итү системасын куллану карары Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

14. ХАХИКС автомат режимда куркыныч табигать күренешләрен һәм техноген процессларны мониторинглау системаларыннан яки автоматлаштырылган режимда Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе карары буенча кулланыла.

15. Хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны тапшыру халыкка хәбәр итү муниципаль системасы эшчәнлегенең автомат, автоматлаштырылган яисә кул режимында гамәлгә ашырыла ала.

16. Халыкка хәбәр итү муниципаль системасының автомат режимда эшләве куркыныч табигать күренешләрен һәм техноген процессларны мониторинглау системаларыннан идарә сигналлары (командалар) алганда алдан билгеләнгән программалар буенча халыкка хәбәр итү системаларын тоташтыру (эшләтеп җибәрү) өчен вәкаләтле тиешле дежур (дежур-диспетчер) хезмәтләре катнашыннан башка тоташтырыла (эшләтеп җибәрелә).

17. Халыкка хәбәр итү муниципаль системасының автоматлаштырылган режимда эшләвен тоташтыру (эшләтеп җибәрү) билгеләнгән сигналлар (командалар) һәм боерыклар кергәндә, халыкка хәбәр итү системаларын эшләтеп җибәрүгә вәкаләтле тиешле дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре тарафыннан автоматлаштырылган эш урыннарыннан башкарыла.

18. Кулдан эшләү режимында:

1) ГТХТС звеносы белән көндәлек идарә итү органнарының дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре, кешеләргә хәбәр итү системаларын тоташтыруны турыдан-туры алар урнашкан урыннан гамәлгә ашыралар, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны тапшыру өчен элемтә операторларына һәм (яки) массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә заявкалар җибәрәләр;

2) күчмә объектларда кычкырып сөйли торган чаралар, мобиль һәм күтәреп йөртелә торган хәбәр итү чаралары кулланыла.

19. Автомат рәвештә эшләү режимы ХАХИКС өчен төп режим булып тора, шул ук вакытта әлеге хәбәр итү системасы автоматлаштырылган режимда да эшләргә мөмкин.

20. Муниципаль хәбәр итү системасының төп һәм өстенлекле режимы булып автоматлаштырылган режим тора.

21. Халыкка хәбәр итү һәм ашыгыч мәгълүмат сигналларын тапшыру «ВНИМАНИЕ: ВСЕМ!» сигналы биреп, электр челтәрләрен, электрон сиреналар һәм көчле акустика системаларын 3 минутка кадәр тоташтырып, аннары аларны элемтә челтәрләре, шул исәптән телерадиотапшырулар элемтәсе челтәрләре, элемтә операторларының һәм телерадиотапшырулар оешмаларының радиотапшыру һәм телевизион тапшыру станцияләре аша тапшыруларны туктатып торып 5 минуттан да артык булмаган аудио - һәм (яки) аудиовизуаль хәбәрләр (күчмә радиотелефон элемтәсе челтәрләре өчен - цифрлар, буш аралар һәм тыныш билгеләрен дә кертеп, рус алфавитының 134 символыннан артмаган күләмдәге хәбәрләр) тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

22. Әлеге хәбәрләрне өч тапкыр кабатларга рөхсәт ителә (күчмә радиотелефон элемтәсе челтәрләре өчен хәбәр тапшыруны кабатлау алдагы хәбәр тапшыру тәмамлангач кына гамәлгә ашырыла).

23. Факттагы һәм фаразлана торган гадәттән тыш хәлләр турында халык өчен типовой аудио-һәм аудиовизуаль, шулай ук текстлы һәм график хәбәрләр, шәһәрнең БДДХ белән берлектә гамәлдәге ГТХТС звеносының идарә итү органы тарафыннан алдан әзерләнә.

24. Халыкка хәбәр итү һәм ашыгыч мәгълүмат сигналларын вакытында тапшыруны тәэмин итү өчен комплекслы рәвештә түбәндәгеләр файдаланырга мөмкин:

1) электр, электрон сиреналар һәм көчле акустик системалар челтәре;

2) чыбыклы радиотапшырулар челтәре;

3) урам радиофикациясе челтәрләре;

4) кабельле телерадиотапшырулар челтәре;

5) эфир телерадиотапшырулары челтәрләре;

6) күчмә радиотелефон элемтәсе челтәре;

7) җирле телефон элемтәсе челтәрләре, хәбәр итү функциясе булган таксофоннар; элемтә операторлары һәм ведомство элемтәсе челтәрләре; персональ радиочакыру системалары челтәрләре; «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре; күчмә объектларда кычкырып сөйли торган чаралар, мобиль һәм күтәреп йөртелә торган хәбәр итү чаралары.

25. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы кысаларында халыкка хәбәр итүне оештыру һәм халыкка хәбәр итү сроклары турындагы мәсьәләләрне карап тикшерү Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

26. Хәбәр итү һәм ашыгыч мәгълүмат сигналларын тапшырганда шәһәрнең БДДХ дежурлары, шулай ук элемтә операторлары, телерадиотапшыру оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренең эш итү тәртибе Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

27. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы элементлары аның карамагында булган Башкарма комитет, шулай ук даими гамәлдәге ГТХТС, БДДХ звеносы белән идарә итү органнары, элемтә операторлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны санкцияләнмәгән тапшыруны булдырмау буенча оештыру-техник чаралар комплексы үткәрәләр.

## 4 бүлек. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын әзерлектә тоту

28. Хәбәр итүнең муниципаль системасын һәм ХАХИКСны әзерлектә тоту Башкарма комитет тарафыннан оештырыла һәм гамәлгә ашырыла.

29. Халыкка хәбәр итү системаларының әзерлегенә түбәндәгеләр белән ирешелә:

1) халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, даими әзерлек хәлендә тоту һәм куллану өлкәсендә актуальләштерелгән норматив актлар булу;

2) халыкка хәбәр итү системасын эшләтеп җибәрү өчен җаваплы дежур (дежур-диспетчер) персоналы булу һәм аның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе;

3) техник хәбәр итү чараларын әзерлектә тоту өчен җаваплы техник хезмәт күрсәтүче персонал булу һәм аның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе;

4) техник хәбәр итү чараларының булуы, төзеклеге һәм халыкка хәбәр итү системасына проект-смета документациясенә туры килүе;

5) элемтә операторлары элемтә челтәрләренең әзерлеге;

6) халыкка хәбәр итү системаларының әзерлегенә даими тикшерүләр үткәрү;

7) вакытында эксплуатация-техник хезмәт күрсәтү, техник хәбәр итү чараларының төзек булмаганнарын ремонтлау һәм билгеләнгән эксплуатация ресурсы чыкканнарын алыштыру;

8) резерв хәбәр итү чаралары булу, аларның Россия Федерациясе законнарына туры килүе һәм файдалануга әзерлеген тәэмин итү;

9) халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, шул исәптән камилләштерү буенча чараларны вакытында үткәрү.

30. Халыкка хәбәр итү системаларының әзерлеген контрольдә тоту максатында түбәндәге тикшерүләр оештырыла һәм үткәрелә:

1) хәбәр итү чараларын тоташтырып һәм тикшерү сигналларын һәм мәгълүматны халыкка җиткереп, халыкка хәбәр итү системаларының әзерлегенә комплекслы тикшерүләр;

2) хәбәр итү чараларын тоташтырмыйча, халыкка хәбәр итү системаларының эшләтеп җибәрүгә әзер булуына техник тикшерүләр.

31. Халыкка хәбәр итү системаларының әзерлеген комплекслы тикшергәндә халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы һәм ХАХИКС тикшерелергә тиеш.

32. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын һәм ХАХИКСны комплекслы тикшерүләр елга ике тапкыр үткәрелә, хәбәр итүнең муниципаль системалары автоматлаштырылган системаларының әзелегенә комплекслы тикшерү үткәрү буенча эшче төркем составына гамәлдәге ГТХТС шәһәр звеносы белән идарә итү органы, шәһәр БДДХ вәкилләре, шулай ук элемтә операторлары вәкилләре керә; хәбәр итү чараларын тоташтыру һәм тикшерү сигналларын һәм мәгълүматны халыкка җиткерү мартның һәм октябрьнең беренче чәршәмбесендә көндезге вакытта гамәлгә ашырыла.

33. Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия карары буенча халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын һәм ХАХИКСны өстәмә комплекслы тикшерүләр үткәрелергә мөмкин.

34. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын комплекслы тикшерү нәтиҗәләре буенча акт рәсмиләштерелә, анда тикшерелгән мәсьәләләр, ачыкланган кимчелекләр, аларны вакытында бетерү буенча тәкъдимнәр һәм 578/365 номерлы приказ таләпләре нигезендә билгеләнә торган халыкка хәбәр итү муниципаль системасының әзерлеген бәяләү чагылдырыла.

35. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын һәм ХАХИКСны тоташтыруга әзерлекне техник тикшерүләр БДДХ дежурлары тарафыннан, хәбәр итү чараларын тоташтырмыйча, тикшерү сигналын һәм «Техническая проверка» дигән телдән хәбәрне тәүлегенә бер тапкырдан ким булмаган вакыт аралыгы белән тапшыру юлы белән үткәрелә.

36. Халыкка хәбәр итү системаларын санкцияләнмәгән тоташтыруга юл куймау максатыннан, барлык тикшерүләрне үткәрер алдыннан мәҗбүри тәртиптә оештыру-техник чаралар комплексы үткәрелә.

37. Гадәттән тыш хәл зонасына эләккән, шул исәптән үзәкләштерелгән хәбәр итүнең автоматлаштырылган системалары эшләми торган территорияләрдәге кешеләргә максималь күләмдә хәбәр итүне тәэмин итү өчен техник хәбәр итү чаралары резервы (стационар һәм мобиль) булдырыла.

38. Техник хәбәр итү чаралары резервының номенклатурасы, күләме, булдыру һәм аннан файдалану тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

39. Халыкка хәбәр итү системаларына, шул исәптән 578/365 номерлы приказ белән билгеләнгән халыкка ашыгыч хәбәр итү комплексы системасына карата таләпләр яңа халыкка хәбәр итү системасын планлаштырганда һәм төзегәндә яисә гамәлдәгесен камилләштерү барышында үтәлергә тиеш.

40. Гамәлдәге халыкка хәбәр итү системасын эксплуатацияләүдән чыгару әлеге халыкка хәбәр итү системасының техник чараларының эксплуатацияләү ресурсы тәмамлангач, аны модернизацияләү (реконструкцияләү) һәм яңа халыкка хәбәр итү системасын эксплуатацияләүгә бирү төгәлләнгәч гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева